**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от 20.01.2020** **№ 90**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясеннән үтә торган муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында пассажирлар һәм багажларны даими рәвештә йөртүне җайга салынулы бәяләре буенча гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга киткән чыгымнарның бер өлешен каплау максатыннан пассажир йөртүчеләргә субсидияләр бирү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында**

2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турындагы” Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 нчы елның 6 нчы сентябрендәге 887 нче номерлы “Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидия бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турындагы” Карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 нчы елның 24 нче июлендәге 1157 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясеннән үтә торган муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында пассажирлар һәм багажларны даими рәвештә йөртүне җайга салынулы бәяләре буенча гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга киткән чыгымнарның бер өлешен каплау максатыннан пассажир йөртүчеләргә субсидияләр бирү Тәртибенә” түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.1 нче пунктның 8 нче абзацында “банкротлык” сүзен “аларга карата банкротлык процессы кертелмәгән, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары караган тәртиптә туктатылмаган” сүзләре белән алыштырырга;

2) 3.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Бюджет чараларын алучы буларак баш бүлүче белән субсидия алучы арасында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү турында килешү Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы финанс органы тарафыннан тиешле төр субсидияләр өчен билгеләнгән типовой формасы нигезендә төзелә;

2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникацион челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында

урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Ф. Хәкимуллинга йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин